**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районы**

**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**

**Арча шәһәр Советы**

**422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27**

**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районы**

**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**

**Арча шәһәр Советы**

**422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27**

**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**15 июнь 2023 ел** **№ 102**

**«Арча шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының 2022 елның 24 сентябрендәге 80 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законга, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының “Арча шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 24 сентябрендәге 80 номерлы карары белән расланган Арча шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1. «3. Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне срогыннан алда туктату өчен нигез туган көн булып әлеге гаризаның Арча шәһәр Советына кергән көн тора.»;

1.2.18 статьяның 1 пунктының б пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының,

күчемсез милек милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә алдан хәбәр итеп;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

"Арча шәһәре" муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев